

Боек Ватан сугышы тәмамлануга 76 ел. Илебезнен барлык шәһәр һәм авылларында, шул исәптән Мордовиядә дә, Жинv коненә багышланган тантаналы-истәлекле чаралар узды. Саранскта Жинv Парады vтте.
Бу истәлекле дата безнен барыбыз очен дә аеруча кадерле һәм моһим. Һәр гаиләдә сугыш геройлары - алдынгы сугышта катнашучылар, тылда хезмәт куйган, коч-куәтен кызганмыйча, жинv яулаган, сугыштан сон илне кvтәргән кешеләр турында истәлекләр саклана. «Үлемсез полк» акциясе ботен донья буенча миллионлаган кешеләрне берләштерә. Он- лайн-форматта vтте.      Ельники районы Кvгеш - Акчеево авылында «Жинv бакчасы» утырттылар, авылнын Мәдәният йорты хезмәткәрлә- ре «Георгиевская ленточка»сын барлык халыкка тарату акциясендә катнашты, 9 майда Акчеево батырлары һәйкәленә чәчәкләр салдылар.



Темников районы Тархан авылында Жинv Коненә әзерлек алдан ук алып барылды. Боек Ватан сугышыннан кайтмаган авылдашлары һәйкәленә косметик ремонт ясалды, тирә-ягын чистартып алдылар – тәртип урнаштырдылар. Шундый ук эшләрне тагы Аксел, Ишейки, Караево (Карай), Митрялы, Тювеево (Тәви) татар авылларында да башкардылар.
Ботенхалык бәйрәме – Боек Жинv Конен билгеләп vткәндә, без анын милли горурлык һәм какшамас бердәмлек, каһарманлык һәм Ватанга чиксез мәхәббәт символы булып калачагын анлыйбыз. 9 май конне тантаналы митингта Темников районы СК «Тархановский» белән авыл китапханәсе хезмәткәрләре, «Аксел урта мәк- тәбе»

укучылары һәм укытучылары, Тархан һәм Аксел авыллары халкы белән бергә шәһәр халкы, кунаклар катнаштылар. Митрял авылынын «Сандугачлар» ансамбле Темник шәһәрендә концерт номерлары белән чыгыш ясадылар.
Без һәрбер кешенен явыз дошманны тар-мар итvгә керткән олеше белән хаклы рәвештә горурланабыз. Кызганычка каршы, бvген безгә тыныч тормыш бvләк иткән, кvп коч һәм югалтулар бәрабәренә исән калучылар саны коннән-кон азрак кала. Кайбер авылларда хезмәт ветераннары да калмады инде, сугыш ветераннары турында сvз дә юк. Боек Ватан сугышында катнашучы, Ләмберәдә гомер итvче, 97 яшьлек Касим Садыйк улы Искандяров турында әйтәсе килә. Сезнен алда баш иябез һәм чиксез рәхмәт, Касим Садыкович!
Жинv Коне хормәтенә Ләмберә районы халкы, кvпторле акцияләрдә катнаштылар, бәйрәмне тантаналы vткәрделәр. Мәсәлән, Черемиш авылында Боек Ватан сугышында батырларча хәләк булган авылдашларына мемориал ачтылар. Шулай ук Аксен, Ләмберә, Пензятка, Татар Тавла авылларында да кvпторле чаралар vтте. Кривозерье авылы Мәдәният йорты хезмәткәрләре дә торле-торле акцияләрдә катнашты. Мәсәлән, Мәдәният йорты житәкчесе Манеева Наилә Шайхатдяр кызы «Жинv шәме») («Свеча Победы»)да актив иде, кvпләр «Йортыбыз белән бергә жырлыйбыз» («Поём двором») акциясенә шәхси олешләрен керттеләр...



Рузаевка районы Татар Пешлә авылындагы Сугыш батырлары һәйкәле янанда митинг vтте, чәчәкләр салдылар. Ә Жинv Ко- не алдыннан Татар Пешләсе Мә- дәният йорты, китапханәсе, авыл администрациясе хезмәткәрләре, республикабызнын барлык почмак-ларында тосле, сугыш һәм тыл ветераннарына вакытлыча Мордовия Главасы вазыйфасын башкаручы Артём Алексеевич Здунов исеменнән, Котлау открыткасы белән аш-су наборларын бvләк иттеләр. Татар Пешлә Мәдәният йорты Жинvгә керткән хатын-кызнын тарихи хәтере һәм доньяда тынычлыкны ныгыту проектынын «Зәнгәр яулык» («Синий платочек») флешмобында катнаштылар.
Кадошкино районы китапханәсендә Муса Жәлилнен «Кулъяулык» дигән шигырен русча яттан Ульяна Егорькина Жинvгә һәм авторнын тууына 150-яшьлек юбилеена багышлап сойләде. Шулай ук китапханәче Динара Идрис кызы Альмяшева житәкчелегендә «Боек Ватан сугышы турында китаплар укыйбыз» акциясендә китап соючеләр катнашты.
Ромодан районы Алтар авылында башка акцияләр белән бергә, «Тынычлык кvгәрчене. Балалар сугышка каршы» («Голубь мира. Дети против войны») урам акциясендә актив катнаштылар.
Без һәрвакыт халкыбызнын батырлыгын истә тотачакбыз, жинvчеләр буыны варислары булуыбыз белән чын кvнелдән горурланачакбыз. Мин барыгызга да нык сәламәтлек, тотрыклылык, иминлек, тыныч кvк йозе һәм ин изге теләкләр телим!

**Наилә НАСЫРОВА**